| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2024 елның 29 мае № 38/6

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карарга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы (11.05.2018 № 27/3, 28.09.2020 № 1/5, 03.02.2022 № 16/1, 10.11.2022 № 22/3, 14.12.2022 № 23/9, 13.02.2023 № 25/3 редакциясендә) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи

окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **1 пунктта** «12 688» санын «13 323» санына алмаштырырга;

2) **1 нче кушымтада**:

а) **абзацны**

«Авыл җирлекләре булган муниципаль берәмлекләр Башлыкларына, айлык акчалата түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, түбәндәге бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә:

- хезмәткә түләүнең 11 төркеменә кертелгәннәргә, – елына 10,36 айлык акчалата бүләк;
- хезмәткә түләүнең 12 төркеменә кертелгәннәргә, – елына 9,26 айлык акчалата бүләк.

Авыл җирлекләре булып торучы муниципаль берәмлекләр Башлыкларының урынбасарларына айлык акчалата бүләкләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, түбәндәге бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә:

- хезмәткә түләүнең 10, 11 төркеменә кертелгәннәргә, – елына 10,69 айлык акчалата бүләк;
- хезмәт түләүнең 12 төркеменә кертелгәннәргә, – елына 9,18 айлык акчалата бүләк.»

**түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Авыл җирлекләре булган муниципаль берәмлекләр башлыкларына, айлык акчалата түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, түбәндәге бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә:

- хезмәткә түләүнең 11 төркеменә кертелгәннәргә, – елына 14,12 айлык акчалата бүләк;
- хезмәткә түләүнең 12 төркеменә кертелгәннәргә, – елына 12,86 айлык акчалата бүләк.

Авыл җирлекләре булып торучы муниципаль берәмлекләр Башлыкларының урынбасарларына айлык акчалата бүләкләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, түбәндәге бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә:

- хезмәткә түләүнең 10, 11 төркеменә кертелгәннәргә, – елына 14,5 айлык акчалата бүләк;
- хезмәт түләүнең 12 төркеменә кертелгәннәргә, – елына 12,77 айлык акчалата бүләк.»;

б) **таблицаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ ДАИМИ НИГЕЗДӘ БИЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРГА, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ КОНТРОЛЬ ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ ХЕЗМӘТ ХАКЫ КҮЛӘМЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ**

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 35 272,00 | | | |
| Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары | 31 745,00 | | | |
| Контроль-хисап органы рәисе | 31 745,00 | | | |
| Авыл җирлеге башлыгы урынбасары | | 16 185,00 | | |
| Авыл җирлеге башлыгы | | | | 18 260,00». |

3) **2 нче кушымтаның таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ**

| Вазыйфаның атамасы | Вазыйфаи эш хакы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 34 640,00 |
| Район Советы аппараты Җитәкчесе | 31 443,00 |
| Район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары | 31 176,00 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 31 043,00 |
| Эшләр идарәчесе | 29 178,00 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 28 512,00 |
| Бүлек начальнигы | 24 248,00 |
| Район Башлыгы киңәшчесе | 21 184,00 |
| Район Башлыгы ярдәмчесе | 21 184,00 |
| Район Башкарма комитеты Җитәкчесе ярдәмчесе | 21 184,00 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 21 184,00 |
| Сектор мөдире | 19 585,00 |
| Баш белгеч | 18 786,00 |
| Әйдәп баручы белгеч | 17 454,00 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 13 323,00»; |

4) **3 нче кушымтаның таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ХЕЗМӘТ ХАКЫ КҮЛӘМЕ**

| | Вазыйфаларның исеме | Хезмәт хакы | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Башкарма комитет Җитәкчесе | 21 717,00 | | |
| 2. | Башкарма комитет секретаре | | | 17720,00». |

5) «МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ АЙЛЫК АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ КҮЛӘМЕ ҺӘМ АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТӘРТИБЕ» **7 нче кушымтада** «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров